وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№19 (162). 9 ноябрь 2012 / 25-зөлхиҗҗә-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ


Вакыф – Исламда хәйриячелекнең нигезе ▷2-3◁


Хәнәфи мәзһәбе – татарларның дини традициясе ▷3◁


Исеме дә үзенчәлекле ▷4◁

## Кеше гомере – Аллаһы Тәгаләнең иң зур бүләге

**Кызганыч, илебездә соңгы елларда ислам дөньясының иң күренекле имамнарының, галимнәренең гомерләре өзелде.**

Ислам динендә кеше үтерү зур гөнаһлардан санала: ул ширектән соң икенче урында тора. Шәригать кеше үтерү хокукын, аерым очраклардан кала, беркемгә дә рөхсәт итми. Ләкин бүген кеше гомеренә кул салу гадәти күренеш кебек кабул ителә башлады, куркыныч җинаятьне кылучылар бәндәләр гомерен өзү Аллаһы Тәгалә каршында зур гөнаһ икәнен оныталар.

Хәтта шәригатьтә каралган үч алу мәсьәләсе кеше гомерен саклауны үз эченә ала. Коръәни-Кәримдә болай диелә (мәгънәсе): "Хәтта үч алуга хокук та тормышыгызны үз эченә ала, адәм балалары!" Бу кеше берәүне үтерергә ниятләсә, аның үзен дә үлем көтә дигән сүз. Башка кеше җанын кыю үз үлеменә китерәчәкне аңлау акылы булганнарны җинаять эшләүдән туктата. Шулай итеп, шәригатьнең үч алуны рөхсәт итүе кеше үтерүне тыюны күз алдында тота. Аятьнең мәгънәсе никадәр зурлыгы шунда күренә.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә: "Менә шуңа күрә, Исраил угылларына шулай дип яздык:

- Кем дә кем кеше җанын кыймаганны үтерсә яки дөньяда бозыклык кылмаганны үтерсә, бөтен кешеләрне дә үтергән кебек булыр. Бер җанны коткарып калган кеше бөтен кешеләрне үлемнән коткарган кебек булыр. Пәйгамбәрләребез моңа ап-ачык дәлилләр китерде, әмма моннан соң да аларның күбесе җир йөзендә хәттин аштылар" ("Маидә (Табын)" сүрәсенең 32 нче аяте).

Ибне Габбас бу аятьнең мәгънәсен болай аңлата: "Аллаһы Тәгалә тыйган кешене үтерү барлык кешеләрне үтерүгә тиң". Бу аятьтән Аллаһы Тәгалә алдында милләтенә, яшенә, җәмгыятьтә тоткан урынына һәм башкаларга карамастан, барлык кешеләрнең дә тигез булуы күренә.

Кеше гомере - Аллаһы Тәгаләнең иң зур бүләге, аны Аллаһы Тәгалә генә ала ала. Без исә, Коръәни-Кәрим өйрәткәнчә тыныч һәм мәрхәмәт кылу юлыннан барырга тиешбез.

*Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

## Замана мулласы нинди булырга тиеш?

**7, 8 ноябрь көннәрендә Г.Камал театрында Туфан Миңнуллин әсәре буенча куелган "Мулла" спектакленең премьерасы булды. Яшәү дәверендә күпне күргән яшь кенә егет мулла булып авылга кайта. Аның кайтуының максаты - бетеп барган авылга яңа сулыш өрү. Ислам дөньясындагы ыгы-зыгылы вакытта бу спектакльнең куелуы киң җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты.**

Мулла сүзе фарсылардан кергән, ул укымышлы кеше, укытучы дигәнне аңлата. Алар мәчеттә биш вакыт намаз укыта, дини йолаларны башкара. Мулла - җәмгыятебездә динне тотып торучы, кешеләр колагына Коръән аятьләрен ишеттерүче дә. Тормышка башыаягы белән чумган адәм балаларына ким дигәндә никах, балага исем кушу, кешене икенче дөньяга озатуга багышланган чараларда Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен җиткерү - мулланың төп вазифаларыннан санала. Бүгенге заман кешедән бик күпне таләп итә: һәр җиргә дә җитешү, ишеткән мәгълүматларны анализлап, кирәклесен генә сеңдерү, алгарышны (прогрессны) кабул итеп өлгерү һәм аны тормышыңа кертеп җибәрү. Тормыш мондый хакыйкатьне муллалар алдына да куя. Мәгълүмати һөҗүм заманында синең сүзеңне ишетсеннәр өчен XXI гасыр мулласы нинди булырга тиеш соң? Минемчә, иң беренче чиратта, мулла вазифасын башкаручыга ихлас булу мәҗбүри. Бар җирдә ялганнан туйган адәм баласы ихласлыкны тиз тоя һәм дин әһеленә аннан берни кирәкмәгәнлекне аңлап, хәзрәт биргән киңәшләргә колак салырга мөмкин.

Икенчесе - гыйлем. Мулла вазифаларын башкарырга ниятләгән кешегә дин мәсьәләләрен бар нечкәлекләре белән белү кирәк. Һәм, әлбәттә, дөньяда барган хәлләрдән хәбәрдар булу, үз заманыннан артта калмау, дәвер белән бергә атлау, инновацион технологияләр белән яхшы таныш булу һәм үз эшчәнлегендә аларны куллана белү тиешле.

Өченчесе - кешеләр белән аралаша белү (коммуникабельность). Хәзерге вакытта хезмәткәрләр эзли торган оешмаларның игъланнарына күз салсак, мөһим шартларның берсе булып кешеләр белән аралаша белү сәләте тора. Кешегә үз фикереңне җиткерә белү дә зур роль уйный. Муллага үз вазифаларын башкарганда төрле кешеләр белән аралашырга туры килә: гади хезмәткәр, зур эшкуар, фән эшлеклеләре, тоткыннар, дәвалап булмый торган авыруга дучар булганнар... Күбесенчә, мулла янына үзе хәл итеп бетерә

*(Ахыры 2-3 нче битләрдә.)*

## МӘДРӘСӘЛӘРДӘ СУФИЧЫЛЫКНЫ УКЫТУ НИГӘ КИРӘК?

***Шәригать фәннәре буенча билгеле китапларның кереш өлешләрендә шәригать кануннары өч өлешкә бүленә дип языла:***

1) гакыйдә (дин тәгълиматы);
2) гыйбадәт (Аллаһка табыну);
3) әхлак.

Ислам диненең фәнни тәгълиматы мәсьәләләре белән гакыйдә (дин тәгълиматы) һәм кәләм (мөселман дин гыйлеме) шөгыльләнә. Мөселман хокукын, шул исәптән Аллаһка табынуның гамәли (практик) аспектларына караган белемнәрне дә, фикъһе фәне өйрәнә. Мораль-этик сораулар һәм әхлак нормалары әхлак һәм тәсаувуф фәннәренең өйрәнү предметлары булып торалар.

"Тәсаувүф" сүзе кайбер мөселманнарның аңында бу фани дөньядан баш тарта торган будда, индуистик карашларның төрле формалары, аскетизм һәм дәрвиш тормыш рәвеше белән ассоциацияләнә. Ләкин андый карашлар ни тарихи, ни теоретик чынбарлыкка туры килми. Мөселман галимнәренең күпчелеге тәсаувүфне - максаты күңелдәге яшерен бозыклыклар белән көрәшү һәм шәхесне рухи тәрбияләү булган ислам фәне дип исәплиләр.

Билгеле булганча, хәзерге Россия территориясендә Ислам таралыш алуда, аеруча Алтын Урда чорында, зур рольне суфичылык мәзһәбләре (тарикатьләр) уйнаган. Безнең җирләрдә булган ясәвия,

*(Ахыры 4 нче биттә.)*



## ЯҢАЛЫКЛАР

### МӘДРӘСӘ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ ҺӘМ БЕЛГЕЧЛӘРЕ ӨЧЕН КУРСЛАР ҮТКӘРЕЛӘ

**Казан (Идел буе) федераль университеты базасында 10, 11, 12 һәм 17, 18 ноябрь көннәрендә "Россиянең дөньяви һәм дини мәгарифендә заманча уку-укыту технологияләре" дип аталган һөнәри белемне үстерү курслары үткәрелә.** Әлеге курсларны Этномәдәни мәгариф фәнни-методик үзәге Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә дини мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре һәм белгечләре өчен оештыра.

Курсларда заманча уку-укыту технологияләре буенча белемнәрне ныгытудан тыш, 2012 ел җәендә мәдрәсәләрдә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләренә кагылышлы фикер алышу да көтелә.

### ИЗГЕ ГАМӘЛ ДӘ СӘДАКА

**7 ноябрь көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы "Зәкят" хәйрия фонды Казанның балалар йортында кыз балалар өчен махсус хәйрия чарасы оештырды. Фонд активисты, һөнәре буенча Франциядә белем алган профессиональ парикмахер балаларның чәчләрен кисеп, аларга төрле причёскалар ясады. Шул рәвешле ул үзенең гамәле белән сәдака кылды.**

"Зәкят" хәйрия фонды җитәкчесе Сәетҗәгъфәр хәзрәт Лотфуллин сүзләренә караганда, алга таба фонд активистлары тарафыннан мондый төр акцияләрне даими үткәрү күздә тотыла.

### МОХТАҖЛАРГА КОРБАН ИТЕ ТАРАТКАННАР

**Түбән Кама Җәмигъ мәчете тарафыннан оештырылган корбан итен кабул итү пунктында 1300 килограмм корбан ите җыелган.** "Әлеге итне пакетларга тутыру, бүлү һәм тапшыру ярты атна дәвамында башкарылды", - дип хәбәр иттеләр район мөхтәсибәтеннән. Җирле үзидарә киңәше белән мохтаҗ гаиләләр исемлеге төзелгән. Мәчеткә йөрүчеләр әлеге исемлеккә кергәннәргә корбан итләрен илтеп биргәннәр. Мөселманнар биш йөзләп адрес буенча барып, шәһәрдә яшәүчеләрне бәйрәм белән котлаганнар һәм корбан итләрен тапшырганнар.

### АПАНАЙ МӘЧЕТЕ АПАНАЙ ОНЫКЛАРЫН ҖЫЙДЫ

**8 ноябрьдә Казанның тарихи Апанай мәчетендә танылган дин әһеле, җәмәгать эшлеклесе Габдулла Апанаев нәселе дәвамчылары җыелды.** Әлеге чараны Апанай мәчете, "Иман" мәркәзе белән берлектә "Мөслимә" иҗтимагый оешмасы уздырды.

2011 елның 2 декабрендә Казанның иң борынгы мәчетләренең берсе - Апанай мәчете, унбиш ел дәвам иткән реставрация эшләре тәмамлангач, рәсми рәвештә яңадан ачылды. Билгеле булганча, ул башкалабызда Мәрҗани мәчетеннән соң, 1768-1771 елларда сәүдәгәр Якуп Солтангалиев акчасына төзелгән. XX йөз башына кадәр мәчетнең иганәчеләре булып сәүдәгәр Апанаевлар гаиләсе тора.

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

### ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!

**1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# ВАКЫФ – ИСЛАМДА ХӘЙРИЯЧЕЛЕКНЕҢ НИГЕЗЕ

**Вакыф гарәп телендә "сакларга", "чикләргә" яки "тыярга" дигән мәгънәне аңлата. Исламда бу сүз ниндидер билгеле бер милеккә ия булуны һәм аны билгеле бер файдага яки хәйриячелек өчен саклауны һәм аны шушы конкрет максатлар кысаларыннан тыш, башка өлкәләрдә теләсә нинди куллануны һәм реализацияләүне тыюны аңлату өчен кулланыла.**



Бу билгеләмә - вакыфта куллану вакыты чикләнмәгән шартнамәлеккә туры килә, ягъни, бу - үзләштерелергә һич тә тиеш булмаган, юкка чыкмый торган милек. Шуңа да вакыф җир һәм биналар белән нык бәйле. Ләкин шул ук вакытта китаплар, авыл хуҗалыгы техникасы, терлек, кыйммәтле кәгазьләр, "тере акча" вакыфлары да бар.

Вакыф идеясе кешелекнең үзе кебек үк борынгы. Мөселман хокукы белгечләре Мәккәдә Кәгъбәне (Гарәп ярымутравының көнбатыш өлешендә) төзү - иң беренче вакыфларның берсе дип раслыйлар, чөнки, Коръән ("Әл-Гыймран (Гыймранның гаиләсе)" сүрәсенең 96 нчы аяте) аны кешеләр дини йолалар башкару өчен җыела торган беренче гыйбадәт йорты дип искә ала. Бер икәрмәсез дип әйтерлек, бар җәмгыятьләрдә дә, бар мәхәлләләрдә дә дини йолаларны башкару өчен бүленгән билгеле бер җир кишәрлекләре һәм биналар бар. Гасырлар буена гыйбадәтханәләр (мәчетләр) һәм башка төр корылмалар төзелгәннәр һәм дини практика өчен файдаланылганнар.

Вакыфның башлануы һәм аның төрләре. Ислам тарихында беренче дини вакыф булып Мәдинәдәге Куба мәчете (ул Мәккәдән 400 чакрым көньяктарак урнашкан) тора. Ягъни ул пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) килгәч, 622 елны төзелгән. Ул хәзер дә шул урында тора, тик бераз зурайтылган гына. Алты ай үткәч, Куба мәчете үрнәгенә Мәдинәнең уртасында төзелгән Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) мәчете дә иярә. Мәчетләр һәм күчемсез милекләр мәчетне тәэмин итү өчен сарыф ителүләр белән чикләнәләр. Техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы чыгымнар дини вакыфлар категориясенә керәләр.

Хәйрия вакыфы - вакыфларның икенче төренә керә. Ул җәмгыятьнең ярлы өлешен һәм китапханәләр, фәнни тикшеренүләр, мәгариф, сәламәтлек саклау системасы, тирә-як мохит һәм хайваннар дөньясын саклау, кече бизнеска кредитлар бүлү, парклар, юллар, күперләр, плотиналарны тоту һәм башка шуның кебек халыкның киң катламы мәнфәгатьләренә туры килүче эшчәнлекнең бар төрләрен дә яклау өчен юнәлтелә. Хәйрия вакыфлары Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) үзеннән үк башланып киткәннәр. Сәхабәләрнең берсе үзенең Мәдинәдәге җиде бакчасын вафатыннан соң Мөхәммәд пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) калуын теләгән булган.

Һиҗринең дүртенче елында бу кеше вафат булган. Һиҗри - Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Мәккәдән Мәдинәгә күчкән 622 елдан башлана торган ай календаре. Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) бу бакчаларны кабул итеп алып аларны ярлы һәм мохтаҗлар файдасына хәйрия вакыфы иткән. Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) бу гамәлен аның сәхабәсе, икенче варис Гомәр (Аллаһ аңа ризалыгын бирсен!) кабул итеп алып дәвам иткән. Ул Пәйгамбәрдән (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!): "Гарәп ярымутравының төньяк өлешендә урнашкан Хәйбәр шәһәрендәге бакча белән нишләргә икән?" - дип сораган. Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) аңа: "Әгәр дә теләгегез булса, сез бу милекне вакыф итеп тота, ә аның җимешләрен хәйрия итеп тарата аласыз", - дип бавап биргән. Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) вафатыннан соң (һиҗринең 632 нче елы), тагын башка күп хәйрия вакыфлары барлыкка килеп үз көчләренә кергәннәр.

Вакыфның өченче төре Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) вафатыннан соң, аның икенче варисы Гомәр (Аллаһ аңа ризалыгын бирсен!) (635-645) хакимияте вакытында ук башланып киткән. Гомәр (Аллаһ аңа ризалыгын бирсен!) үзенең Хәйбәрдәге вакыфын язма рәвештә теркәргә теләгәч, ул бу документка шәһадәтлек кылсыннар өчен Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) берничә сәхабәсен чакыртып алган.

Тагын бер Җәбир (Аллаһ аңа ризалыгын бирсен!) исемле сәхабә: "Бу хәбәр барысына да барып җиткәч, алар барысы да үз күчемсез милекләрен вакыфка бирделәр", - дип сөйли. Кайберләре бу вакыфлардан килгән керемнәр һәм бакча җимешләре, иң беренче чиратта, үз балаларына, аларның киләчәктәге нәселләренә тотылуын, бары тик аннан артканнары гына, әгәр дә андыйлары булса, ярлыларга бирелергә тиеш, дип шарт куйганнар. Мондый вакыфлар - нәселдән килгән яки гаилә вакыфлары дип аталалар. Шуңа да, дини һәм хәйрия максатлары белән генә чикләнгән Америкадагы фондлардан аермалы буларак, ислам җәмгыятендәге вакыфлар үз гаиләң һәм киләчәктәге бала-оныкларың өчен дә файдаланырга мөмкинлек бирәләр.

Юридик күзлектән караганда, вакыфка милек хокукы вакыфка элек ия булган кешегә кире кайтарылмый. Кайбер мөселман юристлары вакыфка милек хокукы Аллаһныкы дип раслыйлар. Икенче бирәүләр исә ул табышка ия булучыларныкы (хәзерге финанс һәм юридик терминология белән әйтсәк, бенефициарларныкы) дип исәплиләр, гәрчә аларның бу милке аннан файдалану мәгънәсендә тулы дип атала алмаса да. Чөнки, алар бу милек белән бары тик аны нигезләгән кагыйдәләр кысаларыннан тыш, башка максатларда файдалану хокукларына ия түгелләр. Бу өлкәдә вакыф - фондлар белән идарә итүнең төп принципларыннан аерыла. Фондлар, кагыйдә буларак, милек итеп сатылырга мөмкиннәр. Ә бу исә - куллану срогы чикләнмәгән ия булу хокукы - вакыфларда, фондларга караганда, ныграк чагылган булуны аңлата.

**ВАКЫФНЫҢ ТИПЛАРЫ.**

**Хәйриячелекнең махсус бер төре буларак, вакыфның үз үзенчәлекләре бар.**

***I. Куллану вакытының чикләнмәгән булуы.***

Бу - вакыф итеп бирелгән милек (еш кына күчемсез милек) бөтенләйгә кала икәнлеген аңлата. Вакыфның күчмә милек кебек төрләрен юкка чыгару - авыр һәм озакка сузылган процесс. Андый күчемсез милекне тиңдәш бәясендәге башка милеккә мәхкәмә хуплавыннан соң гына күчерергә була. Андый операцияләр эшләгәч тә, яңа күчемсез милек, шул ук максатлардагы вакыф булып, бенефициарлар өчен элеккечә үк булып кала. Димәк, срогы чикләнмәгән булу - теоретик яктан караганда вакыфның сыйфатлары кимергә тиеш түгел икәнлекне күз алдында тота.

Вакыф эшен документлаштыру һәм саклау өчен вакыфның оештыручылары һәм хөкем органнары өстәмә саклык чаралары

# Исламның хезмәт мөнәсәбәтләренә керешүе

**Ислам принципларының безнең тормышка үтеп керүен төрле позицияләрдән тикшерергә була. Мәсәлән, зәкят түләү проблемасын карарга мөмкин, һәм бу дөрес тә. Зәкят, чыннан да, ислам баганаларының берсе, аны түләми калу кешене коточкыч киләчәккә алып бара.**

Кешенең зәкят түләү буенча бурычы аның булган байлыгына бәйле. Һәм дә бүгенге көндә Россия халкының күп өлеше, принципта, аларга зәкят түләү бурычы йөкләнә алырлык халык категориясенә кертелә алмый. Шуңа да, бу - мөселманнарның икътисади тормышына массакүләм куела торган таләп дип без әйтә алмыйбыз.

Әгәр дә, хәзерге Россиянең массакүләм икътисади мөнәсәбәтләре арасында ислам принциплары урын алырга тиеш булган мөнәсәбәтләрне караган вакытта, бу, әлбәттә, иң беренче чиратта - хезмәт мөнәсәбәтләре.

Бу - кешенең хезмәткә карата булган мөнәсәбәте, аның һөнәр сайлап алуы, эш көненең озынлыгы, эшнең авырлыгы, хезмәт хакы күләме, аның вакытында түләнүе, эш урынында хезмәткәр ия булырга тиешле сыйфатлар, хезмәткәрнең карьера баскычы буенча күтәрелүе, эшләүчеләргә җәза куллану чаралары, аны эшеннән азат итү һәм, ниһаять, пенсиягә чыгару проблемалары.

Без бу процессларның барысын да күзәтеп бара алабызмы, һәм дә, хезмәтнең үзара мөнәсәбәтләре вакытында безнең, я хезмәт куючы буларак, яки эш бирүче буларак, тәртибебез Ислам принципларына туры килү-килмәвен билгели алабызмы соң? Әйдәгез, бүгенге көндә Исламның бу мәсьәләләрнең кайберләренә карата булган позициясенә кыскача сыйфатлама биреп китик.

Хезмәт - Ислам концепциясе буенча диннең бүлеп алып булмый торган бер өлеше. Бу турыда Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) хәдисендә дә әйтелгән: "Рифагә бине Рафиның сүзләре буенча, бер вакытны Пәйгамбәрдән (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!): "Кешенең казанышларының кайсысы иң яхшысы?" - дип сораганнар. Ул: "Бу - кешенең үз куллары белән эшләп яки игелекле сәүдә белән тапкан әйберләредер", - дигән. Коръәндә хезмәт сүзе (әлгамәл) 360 аятьтә, ә аның синонимы әл-фигыль - 109 аятьтә искә алына. Бу аятьләр барысы да хезмәтнең мөһимлеге турында сөйлиләр.

Исламда ниндидер бер белгечлеккә яки эшчәнлек даирәсенә өстенлек бирелми. Аларны сайлап алу - кешенең үз иркендә. Коръәндә (62 нче сүрә, 10 нчы аять): "Намаз укылып бетүгә үк кайсыгыз кая таралыгыз һәм Аллаһтан нигъмәт сорагыз. Аллаһны күп зикер иткән кешенең Сәгадәткә ирешүе ихтимал", - диелгән. Ягъни кеше үзен һәм үз гаиләсе тормышын җитешле итәр өчен файдалы шөгыль белән мәшгуль булырга тиешлеге турында әйтелгән.

Коръәндә Мәрьям радыйаллаһу ганһу (ул Гайсә пәйгамбәрнең анасы) һәм Гайсә пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе булсын!) тарихы турында языла. Бервакыт аның ашарына да, эчәренә дә булмый. Ул пальма агачына сөяләп торган була. Аллаһ Үзенең фәрештәсе аша аңа: "Пальма агачының кәүсәсен селкет, аннан өлгергән, өр-яңа хөрмә җимешләре коелыр", - ди. Коръәнне тәфсир итүчеләр бу аятьнең асылын шулай итеп аңлаталар: әгәр дә Аллаһ теләсә, ул хөрмә җимешләре пальма агачыннан үзләре коелып төшкән булырлар иде, тик Аллаһы Тәгалә безне һәрвакыт хезмәт куярга, барысына да үз хезмәтебез белән ирешергә омтылырга өйрәтә.

Акча эшләгән кеше, иң беренче чиратта, аны үз гаиләсен тәэмин итү өчен тотарга тиеш. Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сүзләрен тапшырган Әбу Һөрәйрәнең шаһитләве буенча: "Аллаһ юлында сарыф иткән бар динарларыгыз (гарәпләрдә кулланыла торган акча берәмлеге) арасында сезнең кол сатып алуга, ярлыларга хәер тарату буенча хатыныгыз һәм балаларыгыз өчен тотылган динарлар арасында (Аллаһы тарафыннан) иң кадерле булып саналучылары - сезнең үз гаиләгез өчен тотылган динарлардыр", - диелгән. Үз гаиләсенә кирәкле булган бар әйберләр белән аны тәэмин итәр өчен тырышып хезмәт куйган кеше, Аллаһка, үз туганнары мәнфәгатьләре турында онытып, көн-төн дога кылучыдан күпкә кадерлерәк булып исәпләнә.

Хәзерге Россия мөселманнары арасына ислам кыйммәтләре үтеп кердеме соң? Бу процессларны ачу буенча социаль тикшеренүләр бармы? Россиялеләр арасында гадел хезмәт куюга мотивация кимүе фонында, мөселманнар арасында хезмәткә мөнәсәбәтнең яхшыруы турында дәлилләр бармы? Моңа җавапларны без киләсе мәкаләләрдә эзләргә тырышырбыз.

**Галим ВАХИТОВ,**
**икътисад фәннәре кандидаты,**
**Россия ислам университетының Ислам икътисады һәм идарәсе кафедрасы мөдире**

# Замана нинди булырга

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

алмаган мәсьәләсе, я ниндидер күңел борчуы булган кешеләр килә. Андый кешегә күңеле кабул итәрлек сүзләрне кирәкле күләмдә һәм үтемле тавыш белән әйтү бик мөһим.

Әхлаклылык әйткән сүзләрең белән гамәлләрең арасында аерма булмауда ул. Тирәюньдәгеләрдә Ислам турындагы күзаллау мөселманнарның гамәлләренә карап барлыкка килә. Муллалар һәрвакытта да динебезнең әхлаклылык күрсәткече булып торалар. Өстәвенә, мулла булу - ул һөнәр генә түгел. Дәүләт оешмаларында кеше иртәнге сигездән кичке бишкә кадәр эшләсә, калган вакытында аның ниләр белән шөгыльләнүе берәүне дә кызыксындырмый.

Ә муллалар тәүлекнең 24 сәгатендә дә халык күз алдында. Әгәр аның гамәлләре вәгазьләрендә сөйләгән сүзләрдән аерылып торса, кешеләр алдында әйткән фикерләренең кыйммәте калмаячак. Шул сәбәпле, үгет-нәсыйхәт бирү хокукы яшәү рәвешеннән килеп чыга. Мулла кешенең шәхси мәнфәгатьләре икенче урынга кала, чөнки тәүлекнең төрле вакытында сиңа кемнеңдер үлеме яки берәр фаҗигале хәл турында хәбәр итәргә мөмкиннәр. Дин әһелләрен мин табиблар белән чагыштырыр идем, табиблар тән яраларын дәваласа, муллалар - җанны-рухны дәвалаучылар.

Инициатив, актив, иҗади - бүгенге күңел ачу урыннары халыкның буш вакытын уздыру өчен төрледән-төрле чаралар табып кына торалар. Исламга халыкны, бигрәк тә яшь буынны җәлеп итү өчен, муллага да үз мәхәллә халкы өчен төрледән-төрле кызыклы, шул ук вакытта файдалы чаралар уздыру лазем.

күрәләр. Бу гаҗәп тә күренергә мөмкин, ләкин күп кенә шәһәр һәм бистәләр мәхкәмәләренең (судларның) XV һәм XVI гасыр документларында вакыф сыйфатлары турында бөртекләп язылган язмалар әлегә кадәр дә булса сакланалар. Андый язмаларның күбесе "исән-сау" һәм аларны Истанбул, Каһирә, Фәс, Димәшкъ (Шам), Кодүс (Иерусалим), Исфахан кебек шәһәрләрнең тарихчылары тикшерә.

***II. Вакыфны нигезләүченең шартнамәсендәге даимилек.*** Вакыф - ирекле хәйрия акты буларак, аны нигезләүче билгеләгән шартларда (әгәр дә алар шәригать кануннарына каршы килмәсәләр һәм аны бозмасалар) гамәл ителергә тиешле. Ә бу исә аннан алынган табышлар бары тик аны нигезләүче билгеләгән максатларда гына кулланыла ала, идарә һәм административ мәхкәмә тарафыннан куелган мәсьәлә, бер яктан - шәригатькә туры килгән вакытта, ә икенче яктан - башкарыла ала торган вакытта үзгәртелә алмый дигәнне аңлата. Вакыфның максатлары үтәлә алмый башласа, аның табышлары шуңа охшаш максатларда файдаланылырга тиешле, әгәр дә алар булмаса, ярлы һәм мохтаҗларга таратылырга тиеш. Вакыф төзү өчен билгеле бер шартлар таләп ителә.

**Алар арасында аеруча мөһимнәре:**

**1. Вакыфка бирелгән мөлкәт күчемсез милек яки ниндидер бер бәягә ия булган әйбер булырга тиеш.** Мөселман җәмгыятендә вакыф җирләре, биналар, дөяләр, сыерлар, сарыклар, китаплар, зәркән (ювелир) әйберләре, кылычлар, авыл хуҗалыгы кораллары һ. б. киң таралган.

**2. Милек даими нигездә тапшырылырга тиеш.** Кайбер юристлар вакытлы вакыфлар барлыгын да таныйлар. Андый вакыфлар бары тик гаилә вакыфлары очрагында гына була алалар.

**3. Вакыфны нигезләүче, аңа юридик яктан туры килергә һәм андый операцияләрне башкаруга сәләтле халәттә булырга тиеш.** Акылы зәгыйфь яки бала булган кеше яисә бу милеккә хокукы булмаган зат вакыф төзи алмый.

**4. Вакыфның максаты, ахыр чиктә, шәригать күзлегеннән караганда да, аны оештыручының нияте буенча да хәйриячелек булырга тиеш.** Димәк, бай кешеләр файдасына вакыф төзү үзеннән-үзе үк мөмкин булмаган эш, чөнки бу - хәйриячелек дип атала алмый.

**Гамир ГЫЙБАДУЛЛИН,**
**Татарстанның Вакыф фонды генераль директоры;**
**Нияз САБИРҖАНОВ**

# Хәнәфи мәзһәбе – татарларның дини традициясе

## Бүгенге көндә яшьләргә традицион ислам турында мәгълүмат җиткерү мөһим

**Татар халкының күп өлеше сөнни юнәлеше эчендә чисталыгын саклап калган ислам динен тота. Татарлар тоткан сөнни дини юнәлеш Әһле-Сөннәт вәл-Җәмәгать исеме астында билгеле. Бу термин астында үзләренең дөньяга карашларына юл тотып, рәхмәтләребез яуган пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) Сөннәте, аның сәхабәләренең, аларның дәвамчылары – табигыйннарның традицияләрен алган мөселман өммәтенең күпчелеге (кайбер белгечләр фикеренчә, дөньядагы мөселманнарының 90 проценты) күз алдында тотыла.**



922 елда хәзерге татарларның бабалары яшәгән Идел Болгарстанында Ислам рәсми дин итеп кабул ителә. Ләкин аңа кадәр үк инде Идел Болгарстанының күп кенә халкы сөнни Исламның дини-хокукый мәзһәбләренең берсе булган хәнәфи мәзһәбендәге ислам динен тоткан булган. Бу борынгы дәүләт территориясендә шул вакытларда ук мәчетләр, мәдрәсәләр булган.

Алга таба регионның исламлашуына аның Иран, Кавказ, Урта Азия белән булган бәйләнешләре һәм мөселман динен таратучыларның эшчәнлеге ярдәм итә. Шуны да әйтеп китәргә кирәк, Ислам Идел буе һәм Урал җирләренә тыныч юл белән килгән, шуңа да Исламның хәнәфи мәзһәбендәге хокукый нигезләре буенча бу җирләр чын Ислам җирләре (дарүл-Ислам) булып исәпләнә.

Шул вакытлардан башлап, Исламның хәнәфи мәзһәбе тарихи рәвештә татарларның дини традициясе булып киткән. Моңа мәзһәбнең башкача фикер йөртүгә карата билгеле бер дәрәҗәдәге толерантлыгы, гадәти җирле хокукны киң куллануы да ярдәм иткән. Мәзһәбкә нигез салучы имам Әгъзам Әбу Хәнифә Ногман ибне Сабит ибне Зута әл-Фариси (һиҗринең 150 нче елында вафат) табигыйннар буынындагы кеше һәм беренче тапкыр ислам хокукын (фикъһе) системага салган галим булган. Дөньядагы сөнни мөселманнарның яртысыннан артыгы шушы дини-хокукый мәзһәб тарафдары. Бу мәзһәб Габбасилар чорында һәм Госман солтаннары вакытында рәсми мәзһәб булып исәпләнгән. Хәнәфи мәзһәбе Россия һәм Бәйсез Дәүләтләр Берлеге (СНГ) мөселманнарының күпчелек өлеше өчен традицион булып исәпләнә.

Хәнәфи юнәлешендәге Ислам һәм рәсми рәвештә бу динне кабул итү – татарларның ата-бабаларын бер халык итеп туплаган, “мөселман” төшенчәсе ата-бабаларыбызның үз иденфикациясенә әйләнгән.

Татар-монгол явы бу өлкәдә артык зыян китермәгән, бу илнең хакимнәре соңыннан үзләре Исламны һәм җирле традицияләрне кабул иткәннәр. Алтын Урда дәверендә һәм аннан соңгы татар ханлыклары чорында да, хәнәфи мәзһәбе өстенлек иткән, ул Идел-Урал төбәге мөселманнарын берләштергән.

Үз тарихларының авыр чорларында да, үз дәүләтчелекләрен югалткач та, татарлар үз милли үзенчәлекләрен саклап кала алганнар, моңа шактый дәрәҗәдә дини фактор, мөселман дөньясының бер өлеше булулары да зур ярдәм иткән. Казан ханлыгы яуланган вакытта татарларның каршылык күрсәтүләрендә дини подтекст та булган.

Татарлар сөнни Исламның хәнәфи мәзһәбен тотуларының мөһим бер өлеше булып, алар бу мәзһәбнең матуридилык тармагы тарафдарлары булуын да әйтеп үтәргә кирәк. Тарихи яктан барлыкка килүе буенча, хәнәфиләрнең күп өлеше, шул исәптән татарлар да, сөнни кәләменең матуриди тармагын тоталар.

Сәмәркандтан булган имам Әбу Мансур әл-Матуриди (һиҗринең 333 елында вафат) һәм Басрадан булган сөнни имам Әл-Әшари Исламның сөнни булмаган агымнарына каршы торулары белән билгеле. Әл-Матуриди иманны яңартучы булып исәпләнә, ул Ислам тәгълиматының үз вакытында гомуми рәвештә Әбу Хәнифә белән урнаштырылган нигезләрен формалаштырган һәм аны системага салган.

Димәк, имам әл-Матуриди төзегән дин тәгълиматы Изге Коръәнгә һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) Сөннәтенә нигезләнгән. Әбу Хәнифә мәзһәбе тарафдарлары башка төркемнәрдән аерылып тору өчен үзләрен матуридичылар дип атап йөри башлаганнар.

Мөселманнарның татар милләтеннән булган хәзерге вәкилләре күпчелек очракта дингә карата булган эзәрлекләүләргә дә һәм аннан соң читтән кертелгән Исламны чистарту идеяләре таралуга да карамастан, диннең яңадан тергезелүенең юл башында гына булсалар да, матуридичылык тарафдарлары булып кала бирәләр. Алар үз ата-бабаларының сөнни Ислам карашлары буенча хак юлдан барган булуларын, аларның аңлы рәвештә хәнәфичелек һәм матуридичылыкны сайлап алганнарын аңлыйлар. Чөнки Әбу Хәнифә һәм әл-Матуридиларның тәгълиматы Коръәнгә һәм Сөннәткә, ягъни бу дөньяга, пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) китергән тәгълиматка тулысынча туры килә.

Фикъһе мәсьәләләре шәригатьтә төп мәсьәләләр булып саналмасалар да, бүгенге көндә мөселман татарлар өчен хәнәфи мәзһәбе практикасы буенча дин тоту мәсьәләсе кискен тора. Хәнәфи мәзһәбе буенча дини йолалар башкаручы мөселманнарга, дин һәм мәзһәбләр мәсьәләләре буенча, кагыйдә буларак, җаһил булган башка мөселманнар тарафыннан һөҗүм итү очраклары ешайды.

Изге Коръән һәм Сөннәт хакыйкатьләрен аңлатучы хәнәфи мәзһәбенең дөрес юл икәнлеген актив һәм эзлекле рәвештә аңлата бару мөһим. Совет хакимиятенең авыр елларында өлкән буын вәкилләренә ничек итеп диннәрен саклап, ә үзләренең гамәл кылучы мөселманнар булып кала алулары турында яшьләргә аңлату һәм үгет-нәсыйхәтне җиткерү аеруча мөһим. Россиядә дингә һәм Исламның абруйлы кешеләренә карата алып барылган репрессияләр һәм эзәрлекләүләр елларында исә мөселманнар Аллаһка сыгыну (тәвәккүл) һәм бар михнәтләрне дә сабыр һәм күндәм генә кичерә алу сәләтләре булу аркасында гына исән-сау кала алганнар. Бар бу михнәтләр аларга Аллаһ тарафыннан иманнары ныклыгын сынау өчен җибәрелгән икәнлеген аңлаганнар. Хәтта шундый катлаулы хәлләрдә дә алар үзләренең ата-бабалары кебек үк хәнәфи мәзһәбенә тугры булып кала алганнар.

**Марат хәзрәт МӘРДАНШИН,**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы әгъзасы,**
**Ютазы районы имам-мөхтәсибе**

# мулласы тиеш?



Муллага көчле рухлы булу кирәк. Аның тирә-янында нинди генә ыгы-зыгылар булуына да карамастан, ул үз максатына, үз идеяләренә тугры булырга тиеш.

Барлык муллаларга да Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгалә сабырлык, көч-куәт насыйп әйләсә иде.

**Фото Камал театрының рәсми сайтыннан алынды.**
**Ландыш ИБРАҺИМОВА**

# Күршем һәм остазым

***Мамадыш шәһәрендә яшәүче Венера Сөләйманова күпләргә үрнәк. "Күршең булса, бай булсын, бирмәсә дә, сорамас", - дигән мәкаль бар халык телендә. Мин аңа тагын "изге күңелле булсын" дип тә өстәр идем. Чөнки шундый кешеләр белән янәшә яшәгәндә тормыш сикәлтәләре онытылып тора.***

Сүзем - күршем Венера Миңнехан кызы Сөләйманова турында. Ул 1938 елның 30 июлендә гаиләдә беренче бала булып дөньяга килә. Биш яшьлек чагында әтисез кала, аны хәтта хәтерләми дә. Ятим үсәнлектән, аңа бик яшьли эшкә тотынырга туры килә. Лубян техникумын яхшы билгеләргә тәмамлый. Соңрак югары белем дә ала. Бөтен хезмәт юлы урман хуҗалыгы белән бәйле. Әбисе аны изгелек кылып яшәргә өйрәтә. Хәзер андый кешеләр сирәк, халык үз эченә бикләнгән, бергә җыелып эч серләрен сөйләшүләр юкка чыгып бара. Әмма Венера Миңнехан кызы кайда гына күренмәсен, аның тирәсендә кешеләр бетми. Чөнки ул бик игелекле, биргән вәгъдәсен беркайчан да үтәмичә калмый, киңәш-табышка бик булган. Берәр йомыш кушсаң, ахырына чаклы үтәмичә тынычланмый. Өенә килеп керсәң, якты елмаеп, ачык йөз белән каршы ала, хәерле юл теләп озатып кала. Мин үзем аны сигез ел беләм. Ислам дине юлында файдалы эшләр эшләргә - мәетләр юарга, Коръән укырга аны чакыралар. Мәет юарга күбрәк мохтаҗ кешеләргә йөри. Аңа ияреп минем дә барганым бар. Остазым исән булганда бу авыр хезмәтне үзләштерәсем килә. Мине дә Аллаһ диненә чакыручы ул булды. Остазымның сүзләреннән дә файдалырак, күркәмрәк сүз юктыр. Мин аны иң изге күңелле кешеләрдән саныйм. Гомумән, күршемдә шундый кеше яшәве белән мин бик бәхетле. Кылган изгелекләре үзенә меңе белән әйләнеп кайтсын.

**Ф.МИНГАЛИЕВА,**
**Мамадыш шәһәре**

# Исеме дә үзенчәлекле

**Апанай мәчете Казан шәһәренең Иске татар бистәсендә урнашкан. Ул Казанда патшабикә Анна Иоанновна боерыгы буенча җимерелгән һәм янган мәчетләр урынына Әби патша Екатерина II яңа ике таш мәчет төзергә рөхсәт биргәч, татар сәүдәгәре Якуп Солтангалиевның ярдәме белән 1768-1771 елларда төзелә.**



Беренче вакытта мәчет бер заллы, сигез кырлы маналы була. 1872 елда архитектор П.И. Романов проекты буенча, мәчеткә төньяктан ике катлы өстәмә бина кушыла, ул беренчел бина белән бер үк стильдә төзелә. 1882 елда мәчет тирәсендә кирпечтән койма эшләнә, анда бер катлы лавка төзелә. Апанай мәчете ТатҮБК Президиумының 1930 елның 6 февральдәге карары нигезендә ябыла. Совет чорында манара, мәчет залларының гөмбәзләре җимерелә, ә эчке як өч катка бүленә. Декоратив элементларның күбесе юк ителә. Бинада балалар бакчасы урнаштырыла. 1995 елда ул "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә тапшырыла, реставрация эше башлана. Бүгенге көндә манара һәм эчке бүленеш төзәтелгән.

Тарихны белү кеше тормышында зур урын алып торырга тиеш. Үткәнне белмәгәннең киләчәге юк, диләр бит халыкта.

Миңа, үз гомерендә күп сынаулар үткән, тормышының кайсы гына чорын алып карама, истәлекле вакыйгаларга бай әби белән танышырга туры килде. Мәзүфәр әби. Исеме дә үзенчәлекле, башкалардан аерылып тора. Танышуымның төп сәбәбе - тарихи вакыйгага барып тоташа. Ул да булса, Апанай мәчетен төзеткән Якуп Солтангалиевка.

Телефоннан сөйләшкәндә дә сүзләре күп иде, шуның өчен үзен күреп сөйләшергә дип өенә юнәлдем.

- Бәләкәй чакта әбиләр сөйләшкәндә тыңлап утыра идем. Алар безнең Якуп бабай бай кеше булган, мәчет салдырган дип сөйләшеп утыралар иде. Якуп бабайның ике малае була. Беренчесе - Ислам исемле, икенчесе - Исмәгыйль. Ислам дигән улын әтисе акча түләп армия хезмәтеннән алып кала. Исмәгыйль белән ниндидер килешмәүчәнлекләре килеп чыга, әтисе аны армия хезмәтеннән алып калмый, - диде ул.

Исмәгыйль хезмәт иткәннән соң Казанга кайтмый, Буа якларына кайтып төпләнә. Шунда өйләнә дә. Исмәгыйльнең улы Ибраһим, аның улы Мәзүфәр әбинең әтисе Мостафа була. Әбинең фамилиясе Измайлова. Ул вакытта шулай фамилияләрне руслаштырып язу "гадәте" булган. (Фамилия чынлыкта Исмәгыйлева булырга тиеш бит.) Ул Тархан (хәзерге Тәтеш) районының Чагылдым авылында туа. Бу авылга беренчеләрдән булып, Мәзүфәр әби әйтүенчә, аның бабасы Ибраһим белән бер чуваш кешесе нигез сала. Шулай итеп, татар-чуваш авылы яши башлый. Ул вакытта авылда татарлар гөрләп торсалар да, бүгенге көндә алар авылда әз генә торып калганнар. Мәзүфәр әбиләр гаиләдә барысы тугыз бала булалар. Кәүсәрия, Җәүһәр, Мәзүфәр, Мирзаҗан, Фоат, Илфас, Рушания, Гөлфируз, Илгизәр. Бүгенге көндә апасы Җәүһәр белән сеңлесе Гөлфируз һәм энесе Мирзаҗан гына исән-сау. Мостафа Бөек Ватан сугышы елларында өлкән сержант булып хезмәт итә. Ул Буага кайтып үлгән. Мәзүфәр әби әтисе турында яңа мәгълүматларны телевизордан күрсәтелгән сюжеттан гына күреп белә. Мәзүфәр әби үзе 4 класс белем ала. Ул вакытта бит инде күрше авылга йөреп укулар була. Бөтен сугыш чоры кешеләре кичергән авырлыклар аның да башыннан үтә: тыл хезмәтчәне була. Урман кисүләрдә катнаша. Еллар үтә тора. Егерме яшь тә булмый әле ул кияүгә чыкканда. Яратып йөргән егете гармунчы була. Аңа бирмиләр. Армиядән яңа гына кайткан егет белән тормыш корып җибәрәләр. Туганнары да Мәзүфәр әбинең кияве мулла гаиләсеннән, яхшы кеше булыр, дип ризалашалар.

Яшь ир читкә йөри, салып кайткалый, кул да күтәргәли башлый. Шулай да, гаилә дип биш ел түзеп тора аның белән Мәзүфәр әби. Аннан соң аерылышалар. Уллары Рәисне берүзе тәрбияләп үстерә. Штукатур-маляр булып эшли. Инде 1954 елдан бирле Казанда яши ул. Бер сыналса сынала бит ул адәм баласы. Бар да үз көенә генә барганда, улының командировкага киткән җиреннән үле гәүдәсе генә кайта. Аңа бары тик 26 яшь кенә була әле бу вакытта. Шулай итеп, Мәзүфәр әби ялгызы гына торып кала. Бүгенге көндә берүзе генә яшәп ята.

Моңынчы халыкка билгеле дә түгел иде бит әле Апанай мәчетен салдыручы Якупның оныкчыклары турында. Мәзүфәр әбигә бер көнне төш керә. "Имеш, мин өйдә юк икән, ди. Улым гына өйдә икән, ди. Әти улыма документлар биреп калдырган икән, дим. Менә шушы төштән соң Апанай мәчете турында телевизордан күрсәттеләр. Төшләр бит юкка гына керми. Ниндидер хикмәте бар инде моның дим", - дип уртаклашты ул.

Мәзүфәр әби белән сөйләшү мине күп вакыйгалар эченә алып кереп китте, тарихка янә бер кат алып кайтты. Ул шундый ачык йөзле. Аңа карасаң, авырлыкларга юлыккан дип уйламыйсың да. Декабрьдә аңа 80 яшь тула. Аллаһы Тәгалә аңа шатлыклы картлык насыйп итсен.

**Сөмбел ШӘРИФУЛЛА,**
**КФУ студенты**

# МӘДРӘСӘЛӘРДӘ СУФИЧЫЛЫКНЫ УКЫТУ НИГӘ КИРӘК?

***(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)***

нәкшибәндия, кубравия мәзһәбләре үзенчәлекле мөселман мәдәнияте формалашуга зур өлеш керткәннәр, аеруча әдәбиятта, шигъриятта, Исламны аңлауда, аңа интерпретацияләр бирүдә [Якупов В. Мусульманская культура в общественной сфере. - Казань: Иман, 2007. - С. 3].

Шуңа күрә дә безнең шәкертләр, атаклы фәкыйһ, мөфәссир, мөхәддисләрдән тыш, Харис Мөхәсиби, Җүнайд Багдади, Габделкәрим әл-Кошайри, Әхмәд Ясәви, Баһаведдин Нәкышбәнди, имам Раббани кебек башка бөек мөтәсаввифләрне дә өйрәнергә, хөрмәт итәргә һәм сөяргә тиешләр. Аларның үгетләре белән күп кешеләрнең күңеле Ислам нурына коенды, бозыклыклардан тазарынды, Аллаһы Тәгаләгә сөю белән тулды һәм Аның рәхмәтен яуларга омтыла башлады.

Безнең шәкертләргә суфичылык тарихы буенча фәнни эшләр (курс һәм чыгарылыш эшләре) язарга, татар галимнәренең бу фән турындагы хезмәтләрен өйрәнергә кирәк. Чөнки безнең мирас тәсаувүф белән нык бәйле. Шул вакытта гына алар чын суфичылыкны ялган суфичылыктан аера беләчәкләр, дөрес һәм аңлаешлы итеп тәсаувүфның максатын һәм ысулларын аңлата алачаклар. Бүгенге көндә тәсаувүфны пропагандалаучы һәм алар суфичылык тарафдарлары дип раслаучы төркем һәм агымнар бик күп. Шуңа да сак булырга кирәк, чөнки күпләр суфичылыкны ялгыш аңлыйлар. Ә бу ялгыш аңлау Коръән белән Сөннәткә каршы бара торган инструкцияләр буенча эш кылуларга, шундый ялгыш гамәлләргә китерә.

Күптән түгел тәсаувүф тарихын Россия ислам университетында укыта башладылар. РИУ студентлары тәсаувүф темасы буенча бик яхшы хезмәтләр эшләделәр. Аерым предмет буларак, тәсаувүф тарихын мөселман югары уку йортларында гына түгел, ә урта мәдрәсәләрнең соңгы курсларында да укытырга кирәк дип исәплим. Мәсәлән, Казан ислам колледжында бу предмет III курста атнасына бер дәрес укытыла.

Әйтеп китәргә кирәк, Вәлиулла хәзрәт тәсаувүф тарихын, аның максат һәм тәрбия ысулларын укытуның мөһим икәнлеген аңлап, суфичылык турында аз булманган санда китаплар бастырып чыгарды. Мәсәлән, Сүрия галимнәре хезмәтләренең тәрҗемәләрен. Шулар арасында Йосыф Хаттар Мөхәммәднең "Суфичылык энциклопедиясе" һәм шәех Сәед әфәнде Чиркавиның "Файдалы белемнәр хәзинәсе" (татар телендә), Әбу Хәмид әл-Газзәлинең "Бәхет элексиры" һ. б.

"Иман" нәшриятында татарларда суфичылык тарихы, Әхмәд Ясәви, Суфи Аллаһияр, Мәүлә Колый һәм безнең халык бик яратып укыган һәм хөрмәтләгән башка төркитатар суфи шагыйрьләре әсәрләре буенча күп китаплар нәшер ителде.

Мәкаләмнең ахырында билгеле дин галиме, фәкыйһ, һиҗринең II гасыры мөхәддисе Габдулла бине әл-Мөбарәкнең сүзләрен китерәсем килә: "Без күп белемннәргә ия булуга караганда, элементар әдәпкә (тәрбиялелеккә) күбрәк мохтаҗ". Бу сүзләр бүгенге көндә дә актуаль. Бүген шәригать белемнәрен теләгән һәр кеше дә ала ала. Ләкин чын мөселман булу өчен бу гына җитми, югары әхлак сыйфатларына да ия булырга кирәк. Ягъни алган белемнәребез аркылы без тискәре сыйфатлардан арынырга, яхшыларын тупларга тиешбез. Тәсаувүф тарихы предметын өйрәнү безнең шәкертләргә Исламның рухи-әхлакый якларын тирәнрәк аңларга ярдәм итәчәк, безнең өчен үрнәклек өлгесе булган тәсаувүф шәхесләренең тормыш эшчәнлеге белән танышырга мөмкинлек бирәчәк.

**Нияз САБИРОВ,**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең**
**Голамәләр шурасы әгъзасы,**
**Казан ислам колледжының**
**директор урынбасары**

# *Казанда намаз вакытлары*

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 10.11.12 | 6:39 | 8:09 | 13:02 | 15:31 | 16:45 | 18:15 |
| *Якшәмбе* | 11.11.12 | 6:41 | 8:11 | 13:02 | 15:29 | 16:43 | 18:13 |
| *Дүшәмбе* | 12.11.12 | 6:43 | 8:13 | 13:02 | 15:28 | 16:41 | 18:11 |
| *Сишәмбе* | 13.11.12 | 6:45 | 8:15 | 13:02 | 15:27 | 16:39 | 18:09 |
| *Чәршәмбе* | 14.11.12 | 6:47 | 8:17 | 13:02 | 15:26 | 16:38 | 18:08 |
| *Пәнҗешәмбе* | 15.11.12 | 6:49 | 8:19 | 13:02 | 15:25 | 16:36 | 18:06 |
| *Җомга* | 16.11.12 | 6:51 | 8:21 | 13:02 | 15:23 | 16:34 | 18:04 |
| *Шимбә* | 17.11.12 | 6:53 | 8:23 | 13:02 | 15:23 | 16:33 | 18:03 |

# Дини темага рәсемнәр ясап ярыштылар

***4 ноябрь көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы "Зәкят" хәйрия фонды Кабан арты мәчетендә "Аллаһ бу дөньяны яраткан" дип аталган темага рәсемнәр конкурсы үткәрде. Конкурста мәчеттә үткәрелә торган дин сабакларына йөрүче кече һәм мәктәп яшендәге егерме бала катнашты. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар рәсемнәрен кулдан, ә өлкәнрәкләр компьютерда ясады.***

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар арасында беренче урынны Мәдинә Сәлахова, икенче урынны - Ләйсән Хәйретдинова, өченче урынны - Әхмәт Лотфуллин алды. Ә компьютерда их яхшы рәсем ясаучы дип Мөхәммәт Лотфуллин табылды. Икенче урында - Азат Гайнуллин, өченчедә - Илдан Муллин.

Конкурста җиңүчеләргә, катнашучыларга "Зәкят" фонды бүләкләр тапшырды. Моннан тыш, аларга әкият геройлары катнашында бәйрәм оештырылган иде. Соңыннан исә балалар мәчетнең социаль ашханәсендә әзерләнгән табында сыйландылар.



**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 19 (162) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9424.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 8 ноябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**